| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның 18 декабре №33

«Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы Федераль закон, нигезендә «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.«Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Шөгер авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 30.05.2017 №5, 17.11.2017 №22, 29.01.2018 №1, 19.09.2018 №25, 14.12.2018 №38, 22.01.2019 №1, 20.03.2019 №6, 02.10.2019 №23, 12.02.2020 №1, 17.06.2020 №15, 13.08.2020 №17, 12.11.2020 №25, 26.03.2021 №3, 10.08.2021 №20, 28.04.2023 №18, 01.08.2023 №26, 19.10.2023 №35, 18.12.2023 №44, 25.04.2024 №5, 04.10.2024 №24 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 бүлекнең 1.3 пунктында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7.1 пунктында:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль хезмәт вазыйфасын үзе биләгән йә турыдан-туры аңа буйсынган яисә контрольдә тотылган җирле үзидарә органында ышанычлы яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булырга;»;

в) 5_пунктта «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен «муниципаль берәмлектә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6_пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «,сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 9_пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен «һәм аның җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 бүлекнең 8.4 пунктында «, муниципаль берәмлекнең Сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Киров урамы, 17 нче йорт административ бинада, Киров урамы, 23 нче йорт,

«ЛТС» ҖЧҖ-Ленин урамындагы 3 нче Энергорайон, 32 нче йорт, Ленин урамындагы Шөгер СДК, 35 нче йорт, Горький урамындагы Шөгер участок хастаханәсе, 4 нче йорт адресыбуенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Н.Гафиятуллин